*Лиана Әмирханова*

# Чулпы җыры

Балалар өчен җырлар

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2004

УДК 78
ББК 85.319
Ә 53

**Әмирханова Лиана**

Ә 53 Чулпы җыры: Балалар өчен җырлар.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2004.— 64 б.

Әлеге җыентыкка Лиана Әмирханова сүзләренә композиторларыбыз иҗат иткән, республика күләмендә уздырылган балалар җыры конкурсларында диплом алган җырлар тупланды.

ISBN 5-298-01403-8

© Татарстан китап нәшрияты, 2004

# МОҢЛЫ БАЛА КҮҢЕЛЕ...

Болай кистереп әйтүем белән мин, бәлки, бик үк хаклы да түгелмендер. Чөнки ул, балалык чорыннан үтеп, шигъриятътә үзенең җитди сүзен әйтергә байтактан өлгерде. Атаклы язучыларыбыз әсәрләре белән дә, татар халык иҗаты белән дә әле мәктәпкә кергәнче үк таныш булган Лиана беренче шигырьләрен 6 – 7 яшьләрендә үк яза. 10 яшендә аның иҗат җимешләре «Сабантуй» газетасында, «Салават күпере» журналында, төрле күмәк җыентыкларда күренә башлый. Ә 15 яшендә шигырь сөючеләрне ул «Әниемә сыенам» исемле беренче китабы белән сөендерә. Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителгәндә дә аңа нибары 19 гына тулган иде.

Бер караганда, гаҗәп бит?! Хәер, гаҗәпләнергә дә кирәкмидер. Ни дисәң дә, атаклы Әмирхановлар нәселеннән бит ул. Геннар мәртәбәле зыялылардан килә. Иҗатка омтылыш та шуның нәтиҗәсендә тугандыр. Тырышып укуы да, табигый кызыксынучанлыгы да, әнисе Дания Гайнетдинованың язучы булуы да тәэсир иткәндер.

Матурлыкка, камиллеккә омтылуы аны бер үк вакытта нәфис гимнастикага да алып килгән иде. Нәтиҗәләре дә күпләр өчен сөенечле булды. Ул, Пенза, Пермь, Тверь, Арзамас, Тула, Нарва һәм башка шәһәрләрдә үткәрелгән гаять җаваплы ярышларда катнашып, Россия күләмендә призлы урыннар яулады, 1995 елда исә «Россиянең спорт мастеры» дигән мактаулы исемгә лаек булды.

Әдәби иҗат та, нәфис гимнастика да гүзәллеккә сокланудан килеп туган ихтыяҗ. Киләчәктә аларның кайсына өстенлек бирер ул? Миңа калса, Лиана соңгы вакытта шигърияткә ныграк тартыла сыман.

Менә ун еллап инде яшь шагыйрә республика күләмендә уздырылып килгән төрле балалар җырлары конкурсларында актив катнашып, аларда һәрвакыт диярлек беренчелекне яулый.

Менә хәзер, мәктәп балалары репертуарына кергән җырларын туплап, Лиана «Чулпы җыры» дигән яңа китабын тәкъдим итмәкче. Аларның күбесе безгә радио һәм телевидение тапшыруларыннан, яшь һәвәскәрләр

концертларыннан таныш та инде. Композиторларыбыз И.Якупов, М.Имашев, М.Кәшипов, Т.Вәлиев һәм башкалар яшь шагыйрәнең үзләре үк көй, моң сорап торган шигырьләренә игътибар иткәннәр — сүзләренә тиң, күңелгә ятышлы музыка язганнар.

Җыр — шигъриятнең үзенчәлекле жанры. Ул әллә нинди баш катыргыч образлылыкка дәгъва итми. Анда бөтенесе ачык, аңлаешлы, бер ишетүдә отып алырлык булырга тиеш. Гадилектә — осталык.

Тасмамдагы чулпылардан
Челтер-челтер көй тама.
Чулпыларым көй-моңына
Рухи дөньям сафлана,—

ди ул И.Сафин тарафыннан көйгә салынган «Чулпы җыры»нда.

«Юкә алкалары», «Болыт», «Тал песие», «Кояшым», «Уйныйм җил белән», «Бабам истәлеге», «Үсәсем килә», «Кызлар таган атына», «Соңгы кыңгырау», «Чигүле читекләрем» һ.б. җырларында (ә алар утыздан артык) яшь шагыйрә халкыбызның матур гадәт-йолаларын да, балаларның гел шатлыктан гына тормаган бүгенге тормышын да, дөнья һәм туган ил хәлләрен дә үзе генә тапкан отышлы бизәкләр белән сурәтли.

Иҗади эзләнүләренең башы өметле, бүгенгесе ышанычлы аның. Барыр юлың уң, киләчәгең кояшлы булсын, сеңелкәш!

ӘХМӘТ РӘШИТ,
Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе,
Татарстан Язучылар берлегенең
Г.Исхакый исемендәге бүләге лауреаты

# Кар суы

*Илдус Якупов* көе



Челтер-челтер, елтыр-елтыр
Кар сулары юл яра.
— Әйдә,— ди миңа кар суы,—
Китәм, уйнамый калма.

Шырпы кабыннан тиз генә
Мин көймә ясап алдым.
Җилкәннәр куеп көймәне
Ерганак суга салдым.

Көймәне челтер кар суы
Үз артыннан ияртте.
Үзе белән уйнаганга,
Миңа рәхмәтен әйтте.

# *Юкә алкалары*

*Илдус Якупов* көе






Юкәләрнең шау чәчкәдә чагы,
Җемелдәшә алтын алкалары.
Хуш исенә төреп дөнья гамен,
Иренемә тама юкә балы.

Юкәләрнең бүген үсмер кыздай
Иң бәхетле, шау чәчкәдә чагы.
Табигатьнең шушы мизгеленә
Тиңләшерлек җирдә ни бар тагын?


Юкәләрнең шау чәчкәдә чагы,
Иртәләрнең бер гөнаһсыз чагы.
Иренемдә татлы юкә балы,
Күз алдымда алтын алкалары.

# Болыт

Илдус Якупов көе




бер та я ныч сыз ка ла.
Allegro
Кыз:
f
mf
—И ярт ин де, бо лы тым, бер там чың бу лыр и дем. Су са ган гөл -чәч кә ләр нең
бит ләрен ю ар и дем.
8va
--Ба ла чак хы ял ла рың ны а ла мын үзем бе лән. Бү ләк и теп си не җир дә




К ы з :
— Болыт, болыт, мине дә
Иярт син үзең белән.
Сиңа юлдаш булыйм диеп,
Күптән артыңнан киләм.

Б о л ы т :
— Зәңгәр тасмалы дустым,
Мин алсам канатыма,
Син булмагач, чәчкәләр бит
Бер таянычсыз кала.

К ы з :
— Иярт инде, болытым,
Бер тамчың булыр идем.
Сусаган гөл-чәчкәләрнең
Битләрен юар идем.

Б о л ы т :
— Балачак хыялларыңны
Аламын үзем белән.
Бүләк итеп сине җирдә
Калдырам гөлләр белән.


К ы з :
— Болыт, тагын килеп кит,
Безгә ләйсәннәрең сип.

# Тал песие

Илдус Якупов көе




mf
Яшь келт - са ры
mf
mp
тал пе си ен бү лək и тə яз кы зы.
О зак ла мый а ваз са лыр ер га нак та кар су ы.
Allegretto
f
Тал пе си е, тал пе си е — яз ки лү нең бил ге се.
mf




Яздан хәбәр килгән бүген,
Тал песие уянган.
Бу хәбәрне җил малае
Алып килгән урманнан.

К у ш ы м т а :
Тал песие, тал песие —
Яз килүнең билгесе.
Күл өстендә
кояшкайның
Ялт-йолт итә көзгесе.

Яшькелт-сары тал песиен
Бүләк итә яз кызы.
Озакламый аваз салыр
Ерганакта кар суы.

К у ш ы м т а .

Тал песие уянды да
Таң нурында коенды.
Назга сусаган баладай
Яз кызына сыенды.

К у ш ы м т а .

# Чулпы җыры

Ислам Сафин көе





мо‿ цын‿да ру‿хи дөнь‿ям саф‿ ла‿ на.
Чул‿пы‿ла‿рым көй - мо‿ цын‿ да
ру‿хи дөнь‿ям саф‿ла‿ на.
Coda
Чул‿пы‿ла‿рым көй - мо‿ цын‿
да
rit.
ру‿ хидөнь‿ям саф‿ла‿ на.

Тасмамдагы чулпылардан
Челтер-челтер көй тама.
Чулпыларым көй-моңында
Рухи дөньям сафлана.

Челтер-челтер мәңге шулай
Чыңлагыз, чулпыларым.
Чулпыларда туган көйгә
Шытып чыга җырларым.

Тасмамдагы чулпыларым
Көйли гасыр моңнарын.
Чулпыларым чыңнарына
Җырлар үреп җырлармын.

# *Таң йолдызы*

*Ислам Сафин* көе





ка лык тың да ну рың сип тең
дөнь я га. Йол дыз ка ем, бә хет ю ра
1. 2.
из ге юл да ми ңа да. //га зиз ту ган и лем


дә.
Таң йол‿ды‿зым, ну‿ры‿на күм
ү‿ тә‿се юл‿ ла‿ рым‿ ны.
Си‿ ңа тиң‿ лә‿
шә‿ сем ки‿ леп
су‿ за‿ мын кул‿ла‿рым‿ны,
су‿ за‿ мын кул‿ ла‿ рым‿ ны,




Таң йолдызым, калыктың да
Нурың сиптең дөньяга.
Йолдызкаем, бәхет юра
Изге юлда миңа да.

К у ш ы м т а :
Таң йолдызым,
нурыңа күм
Үтәсе юлларымны.
Сиңа тиңләшәсем килеп
Сузамын кулларымны.

Таң йолдызым, үзең белән
Иярт әле мине дә.
Бергә яныйк, бергә балкыйк
Газиз туган илемдә.

К у ш ы м т а .

Йолдызыма җитәр булып
Биеклеккә үрелдем.
Рәхмәт сиңа, таң йолдызым,
Нурларыңа күмелдем.

К у ш ы м т а .

# *Чигүле читекләрем*

*Ислам Сафин* көе




Нә кыш-жеп ләр дән кү нел гә жы лы нур бөр кеп то ра.
Нә кыш-жеп ләр дән кү нел гә жы лы нур бөр кеп то ра.
Чи тек лә рем чи гү ле, чи гү ле, чи гү ле.
Чи гү ле чи тек ләр бе лән би ю лә ре кү нел ле.




Аягымда чиккән читек,
Бизәге көлеп тора.
Нәкыш-җепләрдән күңелгә
Җылы нур бөркеп тора.

К у ш ы м т а :
Читекләрем чигүле,
чигүле.
Чигүле читекләр белән
Биюләре күңелле.

Салават күпере төсе
Җемелди итекләрдә.
Останың кул җылыларын
Тоямын читекләрдә.
К у ш ы м т а .

Биегән саен биетә
Каюлы итекләрем.
Үземә килешеп тора
Чигүле итекләрем.
К у ш ы м т а .

# Изге суз

Ислам Сафин көе




рый сың син, ә ни ем, һәр да им. Са бый
лы гым бе лән о ны тыл сам, ки чер сә нә ми не, Хо да
ем. Хо да ем, ки чер ми не, Хо да ем. Ир тән
1.2.
//ки чер ми не, ки чер ми не, Хо да ем.




Әгузеңне әйттеңме, балам, дип
Сорыйсың син, әнием, һәрдаим.
Сабыйлыгым белән онытылсам,
Кичерсәнә мине, Ходаем.
Ходаем, кичер мине, Ходаем.

Иртән-иртүк күзем ачтым исә,
Искә алам сине, бер Аллам!
Догам кылып, җаным савыктырам,
Синең барлыгыңа табынам.
Табынам синең барлыгыңа.

Син өйрәткән догаларны, әни,
Кабатлыймын көн саен, һәрдаим.
Сабыйлыгым белән онытылсам,
Кичер мине, берүк, Ходаем!

Ходаем, кичер мине, Ходаем.
Кичер мине, кичер мине, Ходаем!

# Соңгы кыңгырау

*Ислам Сафин* көе




1.
2.
мен.
тә.
mf
Мо‿ңай‿ма‿гыз ә‿ле, у‿кы‿ту‿чы‿лар,
са‿гы‿ны‿шып сез‿гә, сез‿гә ки‿лер‿без. У‿рау юл‿лар у‿зып бул‿са да,
сез‿нең хә‿ле‿гез‿не бе‿лер‿без. Мо‿ңай‿ма‿гыз, у‿кы‿ту‿чы‿лар,


са‿гы‿ны‿шып сез‿гә ки‿лер‿без.
У‿рау юл‿лар у‿зып бул‿са
да,
1.
сез‿нең хә‿ле‿гез‿не бе‿лер‿без,
2.
сез‿нең хә‿ле‿гез‿не бе‿лер‿без.
mf
rit.
pp

Чәчкә тотып әле бүген генә
Килгән кебек сиңа, мәктәбем.
Инде менә сезгә, укытучыларым:
«Сау булыгыз!» — диеп әйтәмен.

К у ш ы м т а:
Моңаймагыз әле,
укытучылар,
Сагынышып сезгә килербез.
Урау юллар узып булса да,
Сезнең хәлегезне белербез.

Соңгы тапкыр чыңлый
бу кыңгырау,
Соңгы тапкыр дәшә дәрескә.
Укытучым, синең алда бүген
Сынау тотам соңгы дәрестә.

К у ш ы м т а.

Ел да шулай очар кошлар кебек
Озатып кала мәктәп — изге йорт.
Сабый чакны эзләп бер килербез,
Онытма син, мәктәп, безне көт.

К у ш ы м т а.

# *Татар китабы*

*Илфат Дәүләтшин* көе




cresc.
да. Ки‿нәш‿чем дә бул‿ды, мең со‿рау‿ га жа‿вап та‿
cresc.
бал‿ ма‿ ган ча‿ гым‿ да. Хал‿кым ә‿к(и)ят‿лә‿ ре бе‿лән тәү‿
f
mf
ге тап‿кыр та‿нышт‿тыр‿дың, та‿тар ки‿та‿ бы. Хә‿реф‿ләр‿
дән сүз‿ләр тө‿зү‿ ем дә иң бе‿рен‿че син‿ нән баш‿лан‿




Минем өчен китап изге нәрсә,
Күзем ачты сабый чагымда.
Киңәшчем дә булды, мең сораугa
Җавап табалмаган чагымда.

К у ш ы м т а:
Халкым әкиятләре белән
тәүге тапкыр
Таныштырдың, татар китабы.
Хәрефләрдән сүзләр төзүем дә
Иң беренче синнән башланды.

Рәхмәт сиңа, татар китабы!

Кулларыма алып китабымны,
Серләшәмен ялгыз калган чакта.
Халкымны бит
китап саклап калган,
Хәтта телен, денен җуйган чакта.

К у ш ы м т а.

Адаштырмый әйдәп барасың син,
Нәрсә бар соң сиңа тиң тагын?
Башым иеп сиңа табынамын,
Рәхмәт сиңа, татар китабы!

К у ш ы м т а.

# Балачакта калам


Наил Гарипов көе




cresc.
га. Ак бо лыт лар, әй, сез —
cresc.
mf
ми нем хы ял ла рым,
йөг(е) рек дул кын на
рым...
Сез нең бе лән ка лам,
ба ла чак та ка лам.
ff
Ак бо лыт лар, әй,
cresc.
f



сез —
ми нем хы ял ла рым,
йөг(е) рек дул кын на рым...
Сез нең бе лән ка
rit.
a tempo
3
лам,
ба ла чак та ка лам.
dim.
poco a poco morendo e rit.




Балачакта калам,
Яшел болыннарда.
Яшьтәш булыйк әле
Уйнак колыннарга.

Кушымта:
Ак болытлар, әй, сез —
Минем хыялларым,
Йөгерек дулкыннарым...
Сезнең белән калам,
Балачакта калам.


Балачакта калам,
Ак болытлар белән.
Уйнап арыгач, мин
Яңгыр булып тамам.

Кушымта:
Ак болытлар, әй, сез —
Минем хыялларым,
Йөгерек дулкыннарым...
Сезнең белән калам,
Балачакта калам.

# Күңелне ачыйк әле

*Тәлгат Вәлиев* көе






Табигатьнең, нурга төреп,
Наз бүләк иткән мәле.
Моңга сусады күңелем,
Бер җырлап алыйк әле.
Күңел ачыйк бергә-бергә,
Безнең шундый чагыбыз.
Җырыбыз сезгә ошаса,
Бергәләп кул чабыгыз.

К у ш ы м т а :
Әйдә, кил әле,
бергә җырлашыйк әле,
Әйдә, кил әле,
күңелне ачыйк әле.

Җырлый-җырлый биик әле,
Биик әле арганчы.
Күңел ачып калыйк әле,
Гармунчыбыз талганчы.
Син дә уйна, син дә кушыл,
Шатлыкларны бүлешик.
Чәчкәсе булып илемнең,
Бергә дус булып яшик.

К у ш ы м т а :
Әйдә, кил әле,
бергә җырлашыйк әле,
Әйдә, кил әле,
күңелне ачыйк әле.

# *Бабам истәлеге*

*Тәлгат Вәлиев* көе

*Бөек Җиңүнең*
*50 еллыгына багышлана*


Бу медальләр сөйли миңа
Бабам үткән сугыш юлын.
Медальләрнең чыңнарыннан
Калтыранып куя кулым*.

**Tempo di marcia**




* Бу куплетны җырчы, кулына медальләр тоткан килеш, шигырь итеп укый.


ме даль лә рен а лам ку лы ма.
Ба бам ның ис
тә лек лә рен ме даль ләр сөй ли ә нә.
Ба бам үт кән юл лар буй лап сә я хәт кы лам я
нә. Ба бам үт кән юл лар буй лап




Шактый еллар үтте инде
Бабаемның вафатына.
Юксынганда мин еш кына
Медальләрен алам кулыма.

К у ш ы м т а:
Бабамның истәлекләрен
Медальләр сөйли әнә.
Бабам үткән юллар буйлап
Сәяхәт кылам янә.

Җансыз тимер медальләрдән
Дары исе аңкып тора.
Әйтерсең лә минем алда
Бабам үзе басып тора.

К у ш ы м т а:
Бабамның истәлекләрен
Медальләр сөйли әнә.
Бабам үткән юллар буйлап
Сәяхәт кылам янә.

# Үсәсем килә минем

*Мәсгут Имашев* көе

**Allegretto** ♩=120






Берәү, икәү, өчәү, дүртәү —
Бик озак шул көтәсе.
Минем дә бит сезнең кебек
Килә тизрәк үсәсе.

К у ш ы м т а :
Эх, тизрәк үссәмче,
Дәү кыз булып
җитсәмче.
Ничек тизрәк үсәсе,
Дәү кыз булып җитәсе?

Табак-савыт юар идем,
Урындыкка басмыйча.
Кибеткә дә йөрер идем,
Юл аша курыкмыйча.

К у ш ы м т а .

Уенчык, курчакларымны
Калдырып торыр идем.
Китап-дәфтәрләрне алып,
Мәктәпкә барыр идем.

К у ш ы м т а .

Берәү, икәү, өчәү, дүртәү —
Бик озак шул көтәсе.
Берәр серен әйтегезче,
Килә тизрәк үсәсе.

Кушымта.

# Кояшым

*Марс Кәшипов* көе




нур ла рың да тир бә лим. Әй дә ле, кер ку е ны ма, си не дә бер
1.2.
3.
ир кә лим. //ир кә лим. А...


rit.
a tempo
Ко яш, ко яш, ко яш ка ем, нур ла рың да




Кояш, кояш, кояшым,
Бигрәк иртә торасың.
Алтынсу нурларың белән
Иркәләп уятасың.
Кояш, кояш, кояшкаем,
Нурларыңда тирбәлим.
Әйдәле, кер куеныма,
Сине дә бер иркәлим.

Кояш, кояш, кояшым,
Бик иртә уянасың.
Салават күпере аша
Яңгырга елмаясың.
Кояш, кояш, кояшкаем,
Нурларыңда тирбәлим.
Әйдәле, кер куеныма,
Сине дә бер иркәлим.

# Уйныйм җил белән

*Марс Кәшипов* көе





У‿сал‿лы‿гын жи‿нә тор‿ган, у‿сал‿лы‿гын жи‿нә тор‿ган я‿ше‿рен кө‿чен, се‿рен шул
мин бе‿ләм. Тау шу‿ ган‿ да, арт‿тан э‿ теп, ча‿нам‿
ны жи‿не‿ләй‿ тә.
1.
Тау мен‿гән‿ дә, кар‿шы ки‿леп, тау мен‿гән‿ дә,
кар‿шы ки‿леп бит‿ тән че‿ ме‿ теп ки‿ тә.




Көне буе уйнадым мин,
Кем белән дисезме?
Җил белән.
Усаллыгын җиңә торган
Яшерен көчен,
    серен шул мин беләм.

Тау шуганда, арттан этеп,
Чанамны җиңеләйтә.
Тау менгәндә, каршы килеп,
Биттән чеметеп китә.

Күңелле җылы яңгырым,
Кояшым һәм шаян җилем —
Тормыш юлларымда
юлдашларым.

Әйдә уйныйк, әйдә уйныйк,
Гомер буе гел дус булыйк.
Гомер буе гел дус булыйк,
Дус булыйк.

Әйдә, дуслар,
кулларны тотышып,
Бергәләп җырлыйк әле.
Балачак иленең якты
Йолдызы булыйк әле.

# *Кызлар таган атына*

Фортепиано өчен

*Марс Кәшипов* көе





и теп э леп кап ка ар ты на, чы рык -чы
рык кө ле шә, чы рык -чы рык кө ле шә, кыз лар та ган а ты
на. Чы рык - чы рык кө ле шә, чы рык - чы рык кө ле шә,
1.2.
3.
кыз лар та ган а ты на. //а ты




Дилбегәне таган итеп
Элеп капка артына,
Чырык-чырык көлешә,
Чырык-чырык көлешә,
Кызлар таган атына.

Кызларның күңелләрендә
Нинди сер ята икән?
Җилферди тасмалар,
Җилферди тасмалар,
Җилләргә дәшә микән?

Әйтерсең лә очар кошлар
Дилбегә канатында.
Чырык-чырык көлешә,
Чырык-чырык көлешә,
Кызлар таган атына.

# *Мәктәп сукмагы*

*Марс Кәшипов* көе




Ми‿нем ал‿да бер из‿ ге юл —
мәк‿ тәң‿ кә илт‿ кән сук‿
мак.
Үс‿ мер‿ чак хы‿ ял‿ ла‿ ры‿ ма
ка‿ нат‿ лар өс‿ тә‿ гән чак.
Ак тас‿ ма‿ лы дус‿
тың бе‿ лән
сау‿ бул‿ ла‿ шыр чак жит‿ кән.




Минем алда бер изге юл —
Мәктәпкә илткән сукмак.
Үсмерчак хыялларыма
Канатлар өстәгән чак.

К у ш ы м т а:
Ак тасмалы дустың белән
Саубуллашыр чак җиткән.
Юллар урап кабат килсәм,
Каршы алырсың микән?

Минем алда киләчәкнең
Ачылмаган мең сере.
Ул серләрне йолдызларым
Әйтеп бирерләр әле.

К у ш ы м т а.

Мәктәпкә илткән сукмагым,
Юлдашың итче мине.
Үсмер чагым хатирәсе
Итеп саклармын сине.

К у ш ы м т а.

# Әнием — күз нурым

*Марс Кәшипов* көе

**Moderato**






Әнием — күз нурым,
Әйтерсең фәрештә.
Йөзеңдә нур балкый,
Оста син һәр эштә.

Әнием — күз нурым,
Гүзәлләр гүзәле.
Бары син булганга,
Дөньялар бик ямьле.

Әнием — күз нурым,
Син минем алтыным.
Син минем бәхеткә
Нур булып балкыдың.

# Дуслык жыры

*Айдар Әхмәтшин* көе




Кайларда яшәсә, торса да,
Бер уйда, теләктә балалар.
Бәхеткә юл ярып дусларча,
Салават күпере салалар.

К у ш ы м т а :
Әйдәгез, бергәләп
Куллардан тотышыйк.
Җир шары — уртак йорт,
Шул йортта дус яшик.
Бу җирдә һәркемнең
Бәхеткә хакы бар.
Ятимлек күрмәсен
Дөньяда балалар.


Сабыйлар күңелендә һәрвакыт
Очрашу, бәйрәмнәр еш булсын.
Һәр илдә, һәр җирдә балалар
Бәхеттән, шатлыктан елмайсын.

Кушымта:
Әйдәгез, бергәләп
Куллардан тотышыйк.
Җир шары — уртак йорт,
Шул йортта дус яшик.
Бу җирдә һәркемнең
Бәхеткә хакы бар.
Ятимлек күрмәсен
Дөньяда балалар.

# Гаепләме чичән малае?

*Алсу Салихова* көе






Туган җирем — гүзәл чәчкә иле,
Горур аның хәтта таулары.
Ә мин шушы җирем, халкым өчен
Көрәшүче чичән малае.

Канатлары каерылган кош сыман
Нигез-оям эзләп талпынам.
«Кайда минем
туган Ватаным?» — дип
Сорыймын мин газиз халкымнан.

Бәгырьләре өзелеп, әнкәйләрем
Кочып елый горур кыяларны.
Туган җирен, илен сөйгән өчен
Гаепләме чичән малайлары?

Тауларына гашыйк малайларның
Хыял-канатларын каермагыз.
Ата-баба нигез корган җирдән,
Туган туфрагыннан аермагыз.

# *Әбием баланнары*

*Альбина Сафина* көе






Син утырткан баланнарның
Бик татлы җимешләре.
Тәрәзә аша караса,
Ямьләнә өй эчләре.


Кушымта:
И әбием, баланнарның
Җыйган идең алларын.
Уйладыңмы баланнарның
Истәлеккә калганын?

Песнәкләр дә килеп куна,
Кызыгалар баланга.
Шул баланнар алсулыгы
Күчте хәзер балаңа.

Кушымта:
И әбием, баланнарның
Җыйган идең алларын.
Уйладыңмы баланнарның
Истәлеккә калганын?

# Сөю хисе

*Ганс Сәйфуллин* көе



Мәхәббәтнең тәүге язы,
Бөреләрдә чәчкә исе.
Кыз баланы тетрәндерде
Яз китергән сөю хисе.

К у ш ы м т а:
Табигатьтә ямьле язлар,
Тәүге сөю, татлы хисләр.
Син, мәхәббәт, гомерле бул,
Гашыйк парлар
синсез нишләр?!

Чык тамчысы атылды да
Кызның учларына тамды.
Бер тамчы чык кайнар хистән
Учымда ут булып янды.

К у ш ы м т а.

Рәхмәт сезгә, мәрхәмәтле
Сөю алып килгән язлар.
Учларында учак яккан
Кыз баланы кем соң аңлар?!

К у ш ы м т а.

# *Гөлләрне елатмагыз!*

*Илһам Байтирәк* көе




у‿ ян‿ га‿ нын? Гө‿ наһ‿ сыз са‿ бый ба‿ ла‿ дай ко‿ яш‿ ка ел‿
Soprano
f
май‿ га‿ нын? Гөл‿ лəр е‿ лый да ел‿ ма‿ я, өз‿ мə‿ гез‿ че а‿ лар‿
alto mf
Гөл‿ лəр е‿ лый да, өз‿ мə‿ гез‿ че а‿ лар‿
ны! Жы‿ лы‿ га, наз‿ га су‿ са‿ ган гөл‿ лəр‿ дə ба‿ ла жа‿
ны! Жы‿ лы‿ га су‿ са‿ ган гөл‿ лəр‿ дə ба‿ ла жа‿


ны... Гөл‿ләр е‿лый да ел‿ма‿ я, өз‿ мә‿гез‿
Гөл‿ләр е‿лый да ел‿ма‿ я, өз‿ мә‿гез‿
че а‿ лар‿ ны! Жы‿лы‿га, наз‿ га су‿са‿ ган гөл‿ләр‿дә
че а‿ лар‿ ны! Наз‿ га, жы‿лы‿га су‿са‿ ган гөл‿ләр‿ дә
ба‿ ла жа‿ ны... ны... Гөл‿ләр е‿ лый да ел‿ма‿
ба‿ ла жа‿ ны... ны... Гөл‿ ләр е‿ лый да ел‿ма‿
1.
2.
p



я, өз мә гез че а лар ны! Жы лы га, наз
я, өз мә гез че а лар ны! Наз
га су са ган гөл ләр дә ба ла жа
га, жы лы га су са ган гөл ләр дә ба ла жа
ны, гөл ләр дә ба ла жа ны...
ны, гөл ләр дә ба ла жа ны...

Күргәнегез бармы сезнең
Чәчәкләр уянганын?
Гөнаһсыз сабый баладай
Кояшка елмайганын?

К у ш ы м т а :
Гөлләр елый да елмая,
Өзмәгезче аларны!
Җылыга, назга сусаган
Гөлләрдә бала җаны...

Күргәнегез бармы сезнең
Елаганын гөлләрнең?
Өзелгән сабак очында
Энҗедәй күз яшьләрен?

К у ш ы м т а .

# Эчтәлек

Моңлы бала күңеле... *Әхмәт Рәшит* .....3

Кар суы. *Илдус Якупов* көе .....5
Юкә алкалары. *Илдус Якупов* көе .....6
Болыт. *Илдус Якупов* көе .....8
Тал песие. *Илдус Якупов* көе .....11
Чулпы җыры. *Ислам Сафин* көе .....14
Таң йолдызы. *Ислам Сафин* көе .....16
Чигүле читекләрем. *Ислам Сафин* көе .....19
Изге сүз. *Ислам Сафин* көе .....22
Соңгы кыңгырау. *Ислам Сафин* көе .....25
Татар китабы. *Илфат Дәүләтшин* көе .....28
Балачакта калам. *Наил Гарипов* көе .....31
Күңелне ачыйк әле. *Тәлгат Вәлиев* көе .....34
Бабам истәлеге. *Тәлгат Вәлиев* көе .....36
Үсәсем килә минем. *Мәсгут Имашев* көе .....38
Кояшым. *Марс Кәшипов* көе .....40
Уйныйм җил белән. *Марс Кәшипов* көе .....44
Кызлар таган атына. *Марс Кәшипов* көе .....47
Мәктәп сукмагы. *Марс Кәшипов* көе .....49
Әнием – күз нурым. *Марс Кәшипов* көе ...52
Дуслык җыры. *Айдар Әхмәтшин* көе ......54
Гаеплеме чичән малае? *Алсу Салихова* көе .....55
Әбием баланнары. *Альбина Сафина* көе .....56
Сөю хисе. *Ганс Сәйфуллин* көе .....57
Гөлләрне елатмагыз! *Илһам Байтирәк* көе .....58

Нотное издание

*Амирханова Лиана Расимовна*

**Звон чулпы**

*Детские песни*

(на татарском языке)

Музыкаль мөхәррире *И.И.Байтирәк*
Мөхәррире *В.Р.Камалиева*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Рәссамы *И.И.Әҗемов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *А.С.Газизҗанова*
Корректоры *Г.Г.Гарифуллина*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән
Оригинал-макеттан басарга кул куелды 7.05.2004. Форматы 60×90 1/8. Офсет кәгазе.
«Школьная» гарнитурасы. Офсет басма. Басма табагы 8,0. Шартлы буяу-оттиск 9,0.
Нәшер-хисап табагы 7,46. Тиражы 1000 экз. Заказ Э-348.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.

http://tatkniga.ru
e-mail: tki@tatkniga.ru

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.
Оригинал-макет подготовлен с помощью пакета программ Jahat™.

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.